СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
27.10.2025

КАРАР
№ 6

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы**
**Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы**
**Регламентына өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар бирә:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карары белән расланган Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы Регламентына (2023 елның 29 маендагы 82 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.Регламентның 35 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Карар кабул ителгәндә депутатларның хәлиткеч тавыш хокукына ия "хуплап" һәм "каршы" бирелгән тавышларның саны тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.».

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзекләндерү,төзү,җәмәгать тәртибен саклау һәм хокукларны яклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов